© Яруллина А. Г., Хәмидуллин Л. Х., 2005

# ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНЕҢ НИГЕЗ ТАШЛАРЫ

**Алсу Яруллина, Лирон Хәмидуллин**



АЛСУ ГЫЙНИЯТ кызы ЯРУЛЛИНА – Татар энциклопедиясе институтының энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү бүлеге мөдире. Татар энциклопедиясен төзүдә башлап йөрүчеләрнең берсе.



ЛИРОН ХӘЙДӘР улы ХӘМИДУЛЛИН – язучы, тәрҗемәче. Татар энциклопедиясе институтының өлкән фәнни хезмәткәре. Тататарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.

**Яруллина А.Г., Хамидуллин Л.Х. Краеугольные камни татарской энциклопедии.**

*В статье рассматриваются принципы создания национального энциклопедического словаря, являющегося одним из первых примеров решения государственной задачи по утверждению двуязычия в Республике Татарстан.*

Россиядә 1980 еллар ахыры – 1990 еллар башында күзәтелгән демократик үзгәрешләр зыялыларыбыз күңелендә байтактан бирле бөреләнеп килгән күп кенә ният-омтылышларны тормышка ашыру мөмкинлеген тудырды. Шул исәптән, татар мәгърифәтчеләренең ике гасыр дәвамында милли энциклопедия төзеп чыгару турындагы хыялы да, ниһаять, тормышка ашырылды. 1999 елда татар халкы тарихында беренче мәртәбә "Татар энциклопедия сүзлеге"нең рус телендәге басмасы нәшер ителде. 2003 елның башында шул сүзлекнең берникадәр тулыландырылган һәм 1 меңгә якын яңа мәкаләләр өстәлгән татарча басмасы белән бергә, күләмлерәк, мәгълүматлырак мәкаләләрдән торган "Татар энциклопедиясе"нең русча 1нче томы дөнья күрде.

Бу хезмәтләрнең дөньяга чыгуы татар фәне тарихында гына түгел, Россиянең энциклопедияләр бастырып чыгару тарихында да күренекле бер вакыйга булды. "Татар энциклопедиясе" томнары Татарстан фәненең һәм татар халкының күп гасырлык фәнни-гыйльми хәзинәсен вә акыл сәләтен туплаган бик олы хезмәт ул.

"Татар энциклопедиясе"н нигезләрдәй язма чыганаклар нидән гыйбарәт соң? Аларны без урта гасырлардан башлап барларга тиешбез. Шәрык мәдәниятенең һәм фәненең чәчәк аткан дәверендә – киң карашлы, энциклопедик белемле галимнәр яшәгән урта йөзләрдә – күп кенә житди хезмәтләр язылган. Әбү Насыйр әл-Фәраби, әл-Харәзми, әбү Рәйхан әл-Бируни, Әбугалисина, ибне Фазлан, ибне Рөшд әбү әл-Валид, әбү-л Хәйан Гарнати, әл-Мәсгуди әбү-л Хәсән кебек галимнәр фәлсәфә, тел, тарих, география, астрономия, математика, механика, табиблек, геология һ.б. өлкәләргә караган хезмәтләр тудырганнар. 11 гасырда Мәхмүд Кашгари тарафыннан төрки телләргә багышланган, энциклопедик әһәмияткә ия "Диване лөгат әт-төрк" дигән хезмәт языла (1072-74 еллар). Анда шул чорда мәгълүм булган, Көнчыгыш Алтайдан алып Идел буйларынача таралып зур биләмәдә яшәгән 20ләп төрки кабиләнең сөйләм теле һәм фольклоры үрнәкләре (фонетика, лексика, грамматика), этнография һәм географиясе чагылыш тапкан. Ул хезмәтне шул чордагы төрки телләрнең чагыштырма сүзлеге буларак кабул итәсең.

Гарәп галиме әбү-л Хәйан Гарнати тарафыннан 1313 елда Каһирәдә төрки телләрнең чагыштырма сүзлеге төзелә. 19 йөздә анын кульязмасы Истанбулда "Китаб әл-идракъ лилисан әл-әтрак" исеме белән басылып чыга.

Мисырда мәмлүкләр идарә иткән вакытта яшәгән кыпчак галиме Ала әд-Дин (Аләддин) Байлак әл-Кыпчаки төзегән сүзлек тә игътибарга лаек ("Кәнз әт-тиҗар фи мәгърифәт әләхъяр", 1298 ел).

Борынгы төрки-татар телләренең кыйммәтле тарихи чыганагы буларак 2 дәфтәрдән торган "Коман мәҗмугасы"н ("Codex Cumanicus") атарга кирәктер. Ул хезмәттә 13-14 йөзләргә караган кыпчак-коман сүзләре латин һәм немец телләрендә дә бирелгән. Шунда ук кыпчак телендәге табышмак-әйтемнәр һәм кыпчак теленә тәрҗемәдә Библия сюжетыннан алынган вакыйгалар китерелә. Барлык хезмәт латин хәрефләре белән язылган, сүзлек азагында кайбер сүзләргә карата аңлатмалар бирелгән. Хезмәтне җентекләп өйрәнгән В.В.Радлов сүзлектә теркәлгән кыпчак-коман сүзләренең Идел буе татарлары, бигрәк тә мишәрләр теленә якынлыгын билгеләп үтә [1].

Урта гасырлар галимнәренең эзләнү-табышларын 19 йөздә шәрык һәм бөтендөнья мәдәниятен иңләгән киң карашлы, бай мәгълүматлы Шиһабетдин Мәрҗани (1818-89) дәвам итә. Аның мәгърифәтчелек, дин, тарих, этнография һәм педагогикага багышланган хезмәтләре эшчәнлегенең ни дәрәҗәдә колачлы булуына дәлилдер. Яңарак дөнья күргән бер хезмәттә: "Аның энциклопедик белемен 18 йөз француз мәгърифәтче-энциклопедистлары Дидро һәм Руссо белән тиңләрлек",– дип бик дөрес бәян ителгән [2,*26*]. Ш.Мәрҗани хезмәтләре арасында биобиблиографик сүзлек "Вафиәтел-әслаф вә тәхийәтел-әхлаф" ("Элгәреләрнең гомер саны һәм киләчәк буыннарга бүләге") аерым урын алып тора. Анда шәрык дөньясының мәгълүм 6057 галиме, язучысы, дин әһеле һәм җәмәгать эшлеклесенең биографиясе һәм эшчәнлеге тасвир ителә. Энциклопедияләргә тиң бу хезмәттә шәрык фәлсәфә фәне тарихына һәм фәлсәфәчеләр тормышын-биографиясен барлауга зур урын бирелгән. Китапның кереш өлешендә ("Мөкаддәмә") шәрык илләрендәге фән-гыйлемнең барлыкка килүе һәм үсеше, аның тармаклары тәфсилләп бәян ителә, классификацияләнә. Галимнең икенче зур хезмәте – Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы турындагы 2 томлы зур тарихи китабы ("Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар") тарихи энциклопедия буларак кабул ителә [3]. Бу хезмәтендә Ш.Мәрҗани әлеге ике дәүләтне нигезләүче татар-болгарларның этногенезы мәсьәләсен һәм мәдәниятләренең тарихи дәвамлыгын җентекләп тикшерә. Шунда ук тарих фәне методологиясе мәсьәләсенә дә урын бирелә. Мәрҗанинең өченче зур хезмәте "Китабе гилаләтебез – заман фи тарихи Болгар вә Казан" ("Болгар һәм Казан тарихын каплаучы вакыт пәрдәсе") дә барлык галимнәр тарафыннан хуплана. В.В.Радлов бу хезмәттә Мәрҗани туплаган мәгълүматның бик тә әһәмиятле булуын билгеләп үтә. Хезмәт Бөтенроссия археологларының Казанда уздырылган 4нче съездына багышланган җыентыкта басылып чыга (1878). Ш.Мәрҗани 30дан артык гыйльми хезмәт авторы буларак Россиянең шәркыятьче галимнәре һәм мөселманнары арасында гына түгел, чит мәмләкәтләрдән Төркия, Һиндстан һәм барлык гарәп илләре зыялылары арасында да популярлык казана. "Бөекбританиянең энциклопедияләр нәшер итүче үзәге аның биографик (дөресе: биобиблиографик) белешмәсен һәм фотосурәтен соратып ала" [4]. Мөселман галимнәреннән беренче кеше буларак Шиһабетдин Мәрҗани Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең әгъзасы итеп сайлана, ул җәмгыятьнең эшчәнлегендә актив катнаша.

19 йөзнең икенче яртысында татар халкының күренекле мәгърифәтчесе, энциклопедик белем иясе Каюм Насыйри (1825-1902) да байтак кына мактаулы эшләр башкара. Ул тарих, этнография, тел белгечлеге өлкәсенә караган күпсанлы тирән эчтәлекле хезмәтләр авторы һәм язучы буларак танылa. Татар мәдәнияте тарихы һәм иҗтимагый фикер белгече буларак халык күңелендә тирән эз калдыра. Аның иң күләмле – 609 битле зур хезмәте "Фәвакиһел җөләса, фил-әдәбият" ("Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше") дип атала (1884). Хезмәт 40 бүлектән тора һәм кешеләр тормышта өйрәнергә һәм үтәргә тиешле гыйбрәтле гадәт-мисалларны эченә ала. К.Насыйринең хезмәтләрендә хәтердә уелып калырдай хикмәтле сүз, әйтемнәр байтак. Аның мәгълүм зур хезмәтләреннән тагын берсе тел гыйлеменә карый: татар теленең аңлатмалы сүзлеге буларак танылган "Ләһҗәи татари". Бу хезмәт ике том рәвешендә Казанда 1895, 1896 елларда басылып чыга. Татар тел гыйлеме өлкәсендә кулланылган терминнар эшләнеше шушы хезмәттән башлана. Галимнең тел

белгечлеге өлкәсенә караган хезмәтләре "Ләһҗәи татари"га кадәр дә басылганнар. 1892 елда аның тарафыннан беренче буларак дөрес һәм матур язу кагыйдәләре кулланмасы ("Кавагыйде китабәт") нәшер ителә. 1887 елда 120 битле татар-рус сүзләре ("Кыйраәте рус") китабын, 1891дә рус теле грамматикасын ("Нәмүнә, яки әнмүзәҗ"), 1895 елда татар теленең фәнни грамматикасын ("Әнмүзәҗ") бастырып чыгара. Ташбасмада дөнья күргән иң беренче хезмәте дә татар теле грамматикасына карый: "Кыскача нәхү китабы". Тышлыгына "Краткая татарская грамматика" (1860) дип язылган бу хезмәт русча өйрәнүче татарларны һәм татарча өйрәнүче башка халыкларны истә тотып рус телендә эшләнгән.

Мәгърифәтче галимнең иң беренче әсәре 1859 елда языла, ул "Хәбәрләр җыентыгы" ("Мәҗмәгыл-әхбар") дип атала. 1860 елда табигать күренешләрен чагылдырган, иң беренче әдәби-фәнни-популяр хезмәте булган "Буш вакыт" китабы басылып чыга. 1868 елда К.Насыйри элек 12 битле булган ул хезмәтен күпкә зурайтып, 87 биткә җиткереп нәшер итә. Монысында инде медицинага, кешенең анатомиясен тасвирлауга багышланган бүлекләр дә урын ала. Җир һәм аның кояш тирәли әйләнүе, һава, җил һәм яңгыр күренешләре укыр өчен кызыклы итеп аңлатып бирелә. Соңрак галимнең математикага (1873), игенчелек хезмәтенә ("Гыйльме зирагать", 1892), географиягә (1895), үсемлекләргә ("Гөлзар вә чәмәнзар", 1894) багышланган хезмәтләре, еллык өстәл календарьлары, шәрык дөньясының күренекле әдәби хәзинәләреннән "Мең дә бер кичә"не ("Кырык вәзир кыйссасы", 1868), "Әбүгалисина кыйссы"н (1872), "Кабуснамә"не (1882) тәрҗемә итеп бастыра. Татарча-русча һәм русча-татарча өйрәнүчеләр өчен башкарган сүзлек-ләһҗәләре "Рус хәруф һиҗасе вә зәррә мөрәттиб ләгать китабы" (1892) һ.б. татар дөньясында беренче үрнәкләр булып санала. "Татарча терминологик сүзлекләр төзүнең башлангычы иде", дип бәяли аларны профессор Ф.Сафиуллина [5].

Каюм Насыйриның татарлар тормышкөнкүрешенә, этнографиясенә караган кайбер хезмәтләре Россия күләмендә танылган фәнни журнал һәм җыентыкларда да урын алган. Мәсәлән, аның күләмле "Казан төркиләренең ышанулары һәм ырымнары" мәкаләсе С.-Петербургта "Записки императорского русского географического общества" мәҗмугасының VI чыгарылышында басылган ("Поверье и обряды Казанских татар...", 1880). Үз вакытында нәшер ителмичә калган хезмәтләре, шул исәптән татар этнографиясе материаллары 1926 елда "Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре" китабында дөнья күрәләр.

К.Насыйри 1885 елда Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы итеп сайлана.

Энциклопедик белемле мәгърифәтче, тарихчы, мөселман дине белгече, язучы һәм журналист Ризаэтдин Фәхретдинов (1859-1936) үз гомерендә барлыгы 50 исемдә 147 китап бастыра. Шул күләм чамасында ук әле дөнья күрмәгән кульязма мирасы бар. Аның 4 томлык "Асәр" исемле биоблиографик хезмәтендә Идел буе Болгар дәүләте чорыннан алып 20 йөзгәчә яшәгән 1200дән артык шәхеснең эшчәнлегенә кагылышлы мәгълүмат тупланган. Төп чыганаклар буларак урта гасырлар галимнәре ибне Фазлан, ибне Рөшд, әл-Мәсгуди, әбү Хәмид әл-Гарнати, татар фикер ияләреннән Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов һ.б. хезмәтләренә таяна. Идел буе Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәүләтләре, җәмәгать һәм дин эшлеклеләре, галим вә язучылары, 17 йөз – 20 йөз башында яшәгән мәшһүр затлар эшчәнлеге барланган. "Асәр"нең 15 кисәктән торган 2 томы 1900-08 елларда Казан һәм Оренбург басмаханәләрендә дөнья күрә. Калган 2 томы кульязма килеш РФАнең Уфа фәнни үзәгенә караган Тарих, тел һәм әдәбият институтында, һәм бер өлеше Шәрык белеме интитутының Петербург филиалы архивында саклана. Бу зур хезмәтне бәяләп, академик Миркасыйм Госманов "1917 елга кадәрге татар историографиясе тарихының феномены", дип язды [6]. "Асәр"нең Казан университеты типографиясендә 1900 елда басылган 1нче кисәге университетның фәнни китапханәсендә саклана. Калган 2-15 кисәкләре Оренбургта Гыйльман Кәримев матбагасында дөнья күрәләр. Бу томнарның нәшер ителүе татарлар арасында милли, иҗтимагый фикер үсешенә җитди йогынты ясый.

Олуг галимнең "Асәр"дән соңгы зур хезмәтләре исемлегендә "Мәшһүр ирләр", "Мәшһүр хатыннар" китаплары тора. Анда

Шәрык дөньясында һәм татарлар арасында танылган тарихи шәхесләрнең тормышы тасвирлана. Автор шушы исемнәр белән 20 китап чыгарган. Шулай ук көндәлек матбугат битләрендә 180ләп тарихи шәхеснең тормышын һәм эшчәнлеген тасвирлаган мәкаләләр бастыра.

Риза Фәхретдиновның тарихи хезмәтләрне яисә мәгълүм тарихчының әсәрен шәрехләп бастыру үрнәкләре бар. Мәсәлән, Оренбургтагы Рәмиевләр басмаханәсендә 1915 елда "Ибне Фазланның Болгарга килүе", 1917дә "Ибне Баттутаның Дәшти Кыпчакта сәяхәте" китапларын бастыра. 1897дә Ш.Мәрҗанинның хаҗ кылу сәяхәтен ("Рихләтел Мәрҗани"), 1903тә Оренбург сәүдәгәре Бикмөхәммәдевнең Һиндстан, Төркия аша иленә кайтуын "Исмәгыйль сәяхәте", дип шәрехләп нәшер итә. Басылмыйча калган хезмәтләреннән татар җәмәгатьчелеге өчен иң кыйммәтлесе "Болгар вә Казан төрекләре" китабы (1993 елда нәшер ителде). Р.Фәхретдиновның мәгърифәтчелек карашлары әдәби әсәрләрендә дә чагылыш таба. "Сәлимә, яки гыйффәт" романы 1899 елда Казанда, ә "Әсма, яки гамәл вә җәза" романы 1903 елда Оренбургта басылып чыга. Татар прозасының тәүге күләмле үрнәкләре буларак, бу әсәрләр татар укучысы тарафыннан хуплап кабул ителәләр. Галимнең гаилә мәсьәләләренә кагылышлы "Гаилә", "Нәсыйхәт", "Тәрбияле ана", "Тәрбияле ата", "Тәрбияле хатын", "Тәрбияле бала" китаплары да олуг мәгънәгә ия хезмәтләр. Р.Фәхретдиновның әдәбиятка, тәрбия темасына, дин һәм фәлсәфәгә, тарих, этнография, астрономия, география һәм фәннең башка өлкәләренә караган күпсанлы хезмәтләренең әһәмияте бүген дә югалмаган [2,*35-41*]. Аның энциклопедик эшчәнлеге әле тулаем бәяләнмәгән, кайбер кульязмалары, шул исәптән "Асәр"нең 3-4 томнары әле дә киң җәмәгатьчелеккә җиткерелмәгән. Алар әлегә тар даирә галимнәр тарафыннан гына өйрәнеләләр.

Шиһабетдин Мәрҗанинең замандашы һәм фикердәше мөдәррис мулла Хөсәен Әмирхановның (1816-93) иҗаты бүген шулай ук киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм түгел. Әммә ләкин татар халкының үткәнен барлаучы галимнәр аның колачлы иҗатын югары бәялиләр. Ул иң элек татар телендә Коръән тәфсире "әл-Фәваид"ны язучы буларак танылa. Дин әһеле буларак, ул мөселман дөньясында билгеле бер эз калдырган шәхесләргә багышлап тарихи-библиографик хезмәтләр яза. Аның "Болгар тарихы" ("Тәварихи Болгарийә", 1883), "Йолдызлар тарихы" ("Нөҗүмел тәварих", 1884), "Ерак дәверләрнең бөек шәҗәрәләрен бәян итү" ("Шәҗәрәи Галия фи бәян әл-әснаб", 1884) китаплары Казанда һәм С.-Петербургта нәшер ителәләр. "Галим ул хезмәтләрендә күп кенә тарихи һәм риваяти чыганакларга нигезләнеп, Болгар һәм Казан ханлыклары, Шәрык дөньясы, ислами төрки дәүләтләр дәвере шәхесләренең библиографиясенә кагылышлы байтак мәгълүмат китерә", – ди тарихчы Р.Әмирхан [7].

А.Казимбәк университет өчен 1839да зур күләмле "Грамматика турецко-татарского языка" китабын бастыра һәм соңрак 85 табаклы төрки әдәбият хрестоматиясен әзерли (кульязмада).

Мәгълүм дин эшлеклесе һәм тарихчы Хәсәнгата Габәши (1863-1936) төрки халыкларның үткәнен һәм этник тарихын барлауга багышланган берничә хезмәт язып бастырган: "Төркиләр ыруглары (1897), "Төрки кавемнәрнең кыскача тарихы" ("Мохтасар тарих каум төрки", 1899). Ун елдан соң бу җитди хезмәт тулыландырып нәшер ителә. Дин, тәрбия, педагогика мәсьәләләренә караган хезмәтләре дә берничәшәр мәртәбә басылып чыга. Дингә, фәлсәфәгә карашлары исә миссионер Е.А. Малов китабына карата язылган "Ефим Маловка рәддия" (1886), шәригать кануннарын шәрехләгән "Ысул фикъһ тарихы" (1890) хезмәтләрендә бәян ителә.

Тарихчы, педагог Гайнетдин Әхмәревнең (1861-1911) иҗаты да энциклопедия төзүчеләр өчен кызыклы. Идел буе Болгары чорына нисбәтле Суар шәһәрлеге хәрабәләрен ачучы, Идел-Кама төбәгендә яшәүчеләрнең тарихына, тел үзенчәлекләренә һәм этнографиясенә кагылышлы хезмәтләр авторы. Шулардан иң танылганнары "Болгар тарихы", "Казан тарихы", "Себер тарихы" һәм "Казан ханлыгы" 1906-10 елларда язылa һәм нәшер ителә. Этнографиягә, тарихка караган кайбер хезмәтләре Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте нәшер иткән "Известия ..." фәнни журналында басылалар. Г.Әхмәрев 1904 елда шул җәмгыятьнең әгъзасы итеп сайлана.

Ш.Мәрҗани шәкерте Шәмсетдин Күлтәси (1856-1930) үз заманында мәгърифәтче, фәлсәфәче һәм гыйлем иясе буларак танылган шәхес. 19 йөз ахырларында аның күк җисем-

нәренә (астрономиягә) бәйле рәвешле "Хәйәте җәдидә" (1896), фәлсәфи-астрономик эчтәлекле "Хикмәте җәдидә" (1899), "Җентекле астрономия" ("Мөфассал хәйәте җәдидә", 1920) һәм "Соңгы сүз" ("Мөхакәмәт", 1903) хезмәтләре дөнья күрә. Аларда ул әйләнә-тирә мохиткә фәнни якын килүче, кадимчелекне диндә дә, тормышта да инкарь итүче буларак күзаллана. Казан университеты профессоры, шәркыятьче галим Н.Ф.Катанов аның "Хәйәте җәдидә" хезмәтенә бәя биргәндә, анда Кояш, Җир, йолдызлар һәм аларның хәрәкәте Европа галимнәре дәрәҗәсендә фәнни язылган, ди. Ш.Күлтәсинең "Хикмәте җәдидә" һәм "Мөфассал хәйәте җәдидә" хезмәтләре дә шул ук югарылыкта иҗат ителгән һәм Җиргә, күк җисемнәренә, табигатькә иске карашка капма-каршы килә [2,*66-67*].

Күренекле татар педагогы, тел белгече һәм әдәбият галиме, тәнкыйтьче Җамал Вәлиди (1887-1932) "Татар теленең тулы сүзлеге" авторы. Хезмәтнең 11700 сүзне эченә алган, 2 кисәктән торган 1нче томы 1927-29 елларда языла. Сүзлек тулаем тәмамланмаса да (алфавитның 1нче өлешендәге 15 хәреф кергән), СССРда төрки телдә беренче фундаменталь хезмәт була. Бу хезмәт теоретик нигезләнеше һәм лексикографик принциплары җәһәтеннән бүгенге көн тюркология фәне таләпләренә якын тора.

Күренекле дин белгече һәм тарихчы Морад Рәмзинең (1855-1934) Болгар, Казан ханлыклары чорларына һәм шул дәвер татар хаким-идарәчеләренә, дин әһелләренә багышланган 2 томлы "Тәлфикыл-әхбәр вә тәлкыйхел асар фи вакаигы Казан вә Болгар вә мөлүкет-татар" (Оренбург, 1908) хезмәте үз вакытында киң таралмый кала. Бер-ике йөз данәсе сатылуга, "Христиан диненә һәм руслар хакимиятенә карата нәфрәт тудырган урыннары бар", дип конфискацияләнә. Ләкин үз вакытында Казан университеты профессоры, цензор Н.Ф.Катанов ул хезмәткә карата уңай фикер әйткән була. Казан һәм Болгар патшалыклары тарихын язганда, хакимият вәкилләреннән тыш, шул дәвер рухи тормышыннан да мәгълүмат бирә, дип белдерә [2,*54-58*]. Матбугатта хезмәтне беренче булып Ә.Вәлиди "Морад әфәнде тарихы вә голәмаи Мәрҗани" мәкаләсендә тикшерә.

Казандагы "Касыймия" мәдрәсәсенең элекке шәкерте һәм хәлфәсе мәгълүм тарихчы Әхмәтзәки Вәлидинең (1890-1970) беренче зур хезмәте "Кыскача төрек-татар тарихы" (1912, Казан. 2 нче басмасы 1992 елда чыга) саф татарча язылуы белән үз заманы укучыларын җәлеп итә. Бу китаптан соң галим Казанда яшәү чорында тарихка һәм этнографиягә кагылышлы тагын дистәләгән мәкалә, шул исәптән Ш.Мәрҗанигә, Х.Фәезхановка, Хәлфиннәр династиясенә, Г.Тукайга багышланган хезмәтләр яза.

Энциклопедия тудыруга нигез булырдай зур хезмәтләр иҗат иткән галимнәр исемлеге моның белән генә чикләнми, әлбәттә. 19 йөз – 20 йөз башларында татар халкы арасында иҗтимагый фикер үсеше бик нык алга китә, әмма милли энциклопедия эшләрлек көчләр туплау шарты әле тудырылмый.

Совет хакимияте урнашкач та милли иҗтимагый фикер ияләрен эзәрлекләү чаралары күрелә башлый. 1920 елларда аларның бер өлеше эмиграциягә китәргә мәҗбүр ителә (Г.Исхакый, Г.Баттал, Ф,Туктаров, Ә.Вәлиди һ.б.), калганнарның күпчелегенә фән белән шөгыльләнү мөмкинлеге чикләнә. Рус телендә, татар телендә тирән эчтәлекле хезмәт язып бастырган күренекле фикер иясе Җамал Вәлиди (1887-1932) тиздән кулга алына.

Фәнни-педигогик һәм журналист эшчәнлеген 20 гасыр башында башлаган Әхмәтһади Максуди (1868-1941) укытучылык эшенә, тел белеменә караган хезмәтләре белән таныла. 1927-28 елларда аның күпьеллык эзләнү нәтиҗәсе – энциклопедик хезмәте "Фәнни камус (русча, гарәпчә һәм төркичә фәнни мәҗмугалар буенча тәгъриф кылынган фәнни, әдәби вә сыйнагый истыйлахлар камусы)"ның беренче өлеше дөнья күрә (Казан, "Татарстан" басмаханәсе). Ләкин хезмәт тулаем басылмый. Булачак китабының эчтәлегенә кереш мәкаләдә Ә.Максуди үз бурычын болайрак аңлата: "...вакытлы матбугатта һәм әдәбиятта кулланылган фәнни терминнарның мәгънәсен аңлату өчен мәдәниятле халыклар күптомлы аңлатмалы сүзлекләр төзергә мәҗбүрләр. Тәрәккыять юлына баскан безнең халыкта, вә башка төрки халыкларда шундый хезмәткә хәзер ихтыяҗ зур. Андый эшне башлап җибәрү максатыннан чыгып, минем тарафтан фәнгә, әдәбиятка вә сәнәгатькә караган 10 мең чамасы терминны эченә алган сүзлек тәкъдим ителә" [8].

Сүзлек терминнары 21 бүлеккә һәм 126 параграфка бүленеп бирелгән. Хезмәтнең беренче параграфы: "Белем һәм фән тармакларының гомуми атамалары" дип исемләнә.

Аннан соңгы параграфларда фәлсәфә, математика, физика, химия фәннәре тармаклары, минералогия, нәбатат-үсемлек гыйлеме, хайваннар, антропология, табиблык гыйлеме, иҗтимагый фәннәр, тел белеме һәм әдәбият гыйлеме, тәрбия һәм уку-укыту өлкәсе, тарих фәне һ.б. тәртибе китә. Һәр параграфта күрсәтелгән фән тармагына кергән терминнарга автор тарафыннан кыскача аңлатма урнаштырылган. Сүзлек гарәп алфавитында басыла. Әмма мәкалә исемнәре ("кара сүзләр") баштa рус хәрефләре ("кириллица") белән, аннары гына гарәп язуында бирелгән. Җәяләр эчендә теге яки бу терминның килеп чыгышы күрсәтелгән. Кайбер сүз-терминнарга карата кыскача этимологик белешмә дә өстәлгән. Күпчелек терминнарга автор тарафыннан татарча синонимнар да китерелгән. Ә.Максуди "Фәнни камус"ны 4 томлы итеп чыгарырга ниятләгән була. Әмма хезмәтнең 4 кисәктән торган 1нче томы гына нәшер ителә: 1нче бүлек 48 битле (409 сүз), 2нче бүлек 64 битле (383 сүз), 3нчесе – 55 битле (594 сүз) һәм 4нчесе 159 битле (913 сүз). Ә.Максудиның бу зур хезмәте эчтәлеге белән дә, беренче татар энциклопедиясе үрнәге буларак та әһәмиятле. Галимнең бу фәнни иҗаты әлегә үзенең тикшерүчесен көтеп кала.

Татар энциклопедиясен оештыру-төзү турында берничә буын татар мәдәният эшлеклесе һәм галиме уйлана, күңелендә йөртә. Ә.Максудидан соң да ул хакта хыялланучылар була. Шундыйларның алгы сафында "татар фәнни әдәбиятында яңа жанрны нигезләүне тизләтүче һәм төүге адым ясаучыларның берсе – педагог, галим, Казан педагогия институты профессоры Рифгать Шакирҗан улы Таһиров (1903-77) була [9]. Ул байтак еллар дәвамында Татарстанда яшәүче халык вәкилләренең мәгълүм шәхесләре, галим-зыялылары турында библиографик мәгълүмат туплаган, шул исәптән Советлар Союзы геройлары, Социалистик Хезмәт геройлары, сәнәгатьтә танылган алдынгы хезмәт ияләре, дәүләт эшлеклеләре, галимнәр, артистлар, язучылар һ.б. турында. Ул туплаган 11 папка кулъязманы улы – Вартан Таһиров ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институтына тапшырды. Беренче папка тышына галим тарафыннан "Татарстан" энциклопедик сүзлеге (11 том)" дип язылган. Киң диапазонлы, тәҗрибәле галим Р.Ш.Таһировның татар халкы һәм Татарстан, Россия һәм чит илләр тарихы мәсьәләләренә багышлап 120 фәнни мәкалә язып бастыруы мәгълүм. Әлегә нәшер ителмәгән хезмәтләре арасында "Татарстан тарихчылары" библиографик сүзлеге (1917-77 елларны иңли) дә бар. "Татарстан" энциклопедик сүзлеге" автор тарафыннан төгәлләнмичә кала, шуңа да карамастан аның энциклопедия төзүгә керткән өлеше зур.

Күренекле журналист, матбугат белгече һәм язучы Исмәгыйль Габдулла улы Рәмиевнең (1895-1969) дә энциклопедик эчтәлекле хезмәтләр төзү эшчәнлеге игътибарга лаек. 1926 елда Казанда аның "Вакытлы татар матбугаты" исемле аннотацияле библиографик китабы басылып чыга. Зур күләмле бу китапка 1905-25 елларда Россиядә һ.б. илләрдә татар телендә нәшер ителгән газета, журналлар, аларның мөхәррирләре һәм наширләре исемлеге кергән. 1965 елда И.Рәмиевнең энциклопедик юнәлешле 2нче китабы "Истәлекләр. Татарча басма сүз" дөнья күрә. Шул ук елларда ул, элекке хезмәтләренә һәм Казан университетының гайльми китапханәсе, архив материалларына нигезләнеп, "Әдәби сүзлек" хезмәтен туплый. Автор вафатыннан соң кулъязма белешмәлек байтак еллар дәвамында хәрәкәтсез ята. Татар энциклопедия институтының өлкән фәнни хезмәткәре Рәис Нәүширван улы Даутов тарафыннан редакцияләнеп һәм астөшермә рәвешендә өстәмә мәгълүмат белән тулыландырып, 2001 елда китап буларак басылып чыга (399 бит). "Әдәби сүзлек"тә, нигездә, совет хакимияте урнашканчы татарлар арасында мәгълүм булган шәхесләргә, уку йортларына һәм мәдәният-сәнгать оешмалары эшчәнлегенә караган белешмәләр урын алган. Ул белешмәләрнең кайберләре беренче мәртәбә дөнья күрә һәм шуңа күрә И.Рәмиев белән Р.Даутов нәшер иткән хезмәтнең әһәмияте зур. Шул рәвешле, 19 йөз урталары – 20 йөз башларында байтак кызыклы, энциклопедия өчен бай мәгълүмат туплаган. Алар башлаган зур эшләрне 20 йөз галимнәре дәвам иттерде һәм үстерде. Инде татар зыялыларының хезмәтләрен барлау кирәк.

Әлбәттә, киң колачлы, тирән эчтәлекле

тулы бер энциклопедик хезмәтне төзү аерым бер галимнең генә көченнән килерлек түгел. Хәзерге вакытта энциклопедия төзүне фәннең төрле тармакларында эшләүче бер төркем галимнәр тырышлыгы һәм аларны берләштереп эшләтүче нәшрият яки гыйльми институт тарафыннан гына башкарып була.

Мәгәр, алда санап үтелгән татар зыялылары, фикер ияләре эшчәнлеге яшәешнең барлык өлкәсен, фәннең барлык тармакларын чагылдырган зур бер җитди энциклопедия төзү өчен җирлек, чыганак булып торалар.

ЧЫГАНАКЛАР


1.Радлов В.В. О языке куманов по поводу издания куманского словаря. – СПб., 1884.
2.Духовная культура и татарская интеллигенция. Исторические портреты. – Казань: Магариф, 2000.
3.Мухаметшин Р. Энциклопедия как зеркало нашей жизни // Казань, 2001, №12.
4. Абдуллин Я. Основоположник научной истории татар Шигабутдин Марджани // Казань, 2001, №12.
5.Сафиуллина Ф. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан, 1999.
6.Усманов М.А. Наследие Ризы Фахретдинова // Сов. Татария, 1989, 14 февраля.
7.Амирханов Р.У. Татарская историография. Востоковедческо-тюркологические аспекты // Научный Татарстан, 2000, №3.
8. Сабирзянов Г. "Фәнни камус" А.Н.Максудова // Гасырлар авазы – Эхо веков, 2002, №1-2.
9. Сабирзянов Г., Кадыйров И. У истоков татарской энциклопедии // Респ. Татарстан, 1998, 10 ноября.


© Кушелекова Ф. А., 2005

# ДИМЧЕ - ДИҢГЕЗ КИЧЕРӘ

**Фәридә Кушелекова**



ФӘРИДӘ АМАНГЕЛЬДЫ кызы КУШЕЛЕКОВА – 1999 елда Казан дәүләт университетының Татар теле, әдәбияты, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетын тәмамлап, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты белгечлеге буенча аспирантурада укый. Бүгенге көндә кече фәнни хезмәткәр булып эшли һәм профессор Фатыйх Урманчеев җитәкчелегендә кандидатлык диссертациясе яза.

**Кушелекова Ф. А. Сваты морем проведут.**

*В статье рассматривается первый этап свадебного обряда татар "яучылау – сватание" и анализируются поэтические особенности этого действа.*

Туй, иң беренче чиратта, гаиләләр арасындагы сөйләшү-киңәшүдән – яучылаудан башлана. Күп кенә очракларда ул бернинди дә махсус йола детальләре яки поэтик фольклор әсәрләре белән алып барылмаган. Кайбер очракларда яучылау уңышлы үтсен өчен яучының аерым тышкы билгесе сакланган һәм кыз ата-анасы белән сөйләшүне башлап җибәрү өчен традицион формула-керешләр (мәсәлән: "Баш миннән, кылыч – сездән" һ.б.) кулланылган. Яучылауның рәсми төгәлләнүе булып ярәшү (аклашу, килешү) торган. Моннан соң инде кыз берсүзсез икенче гаиләгә вәгъдә ителгән булып саналган.

Туйга әзерлек егетнең әти-әнисе үтенече буенча кыз өенә, аның әти-әнисенә яучы – башкода җибәрүдән башлана. Бу – туй йоласының рәсми өлеше башлану дигән сүз. Чөнки, гадәттә, кемнең кемгә кияүгә чыгарга җыенуы, кемнең кем кызын кодаларга ниятләве кебек хәбәрләр халык арасында күптән таралган була. Аерым очракларда башкода булып егетнең әтисе яисә сүзгә оста берәр туганы да барган. Шулай да сүзне җитди һәм рәсми рәвештә башлау – бу, барыннан да элек, бөтен авылда, хәтта тирә-якта танылган профессиональ яучы-димче эше. Яучы булып барасы кеше ничек киенергә, ничек барып керергә, үз-үзен ничек тотарга, ничек сүз башларга тиешлеген бик яхшы белә һәм, оста яучы буларак, уңай җавапка ирешә.

Татарларда "яучы" мәгънәсендә башка